ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.07.2026 г. Заинск № 356

**Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 21 декабрендәге 663 номерлы "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүленгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибен раслау турында" карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 08 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законы, ТР МКның «Гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының бүленгән полосалары һәм юл буе полосалары турында» 2008 елның 1 декабрендәге 841 номерлы карары белән, Зәй муниципаль районы Уставының 45 маддәсенә таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 21 декабрендәге 663 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүленгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.3 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«автомобиль юлының юл буе полосалары - автомобиль юлының беренче, икенче яисә өченче категорияле бүленгән полосасына якын урнашкан һәм чикләрендә юл хәрәкәте иминлеге таләпләрен тәэмин итү максатларында җир кишәрлекләреннән (җир кишәрлекләре өлешләреннән) файдалануның махсус режимы, шулай ук автомобиль юлын үстерүнең перспективаларын исәпкә алып,

реконструкцияләүнең, капиталь ремонтлауның, ремонтлауның, аның сакланышын тәэмин итүнең нормаль шартлары билгеләнә торган территорияләр;».

2. Әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында http://zainsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

Магерамова Е.С.
8(85558) 9-90-55